СОВЕТ МОРТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОРТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 162 24.06.2019

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 30 маендагы 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлеге Советы

**КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 30 маендагы 29 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль бурыч алулар җирле бюджет кытлыгын финанслау, шулай ук муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү, финанс елы дәвамында җирле бюджет счетларында калган акчаларны тулыландыру максатларында гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Рәис** **Закиров Ф.Ф.**